ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.09.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2543**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләүгә керешергә.
2. Шәһәр төзелешен зоналаштыру этапларын билгеләргә (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (2 нче кушымта) .
4. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында ( http:zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга .

Җитәкче И. Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына карата
1 нче кушымта
27.09.2022 №2543

**Шәһәр төзелешен зоналаштыру этаплары:**
**җирлек территориясе**

1. Торак зоналар.
2. Иҗтимагый-эшлекле зоналар.
3. Җитештерү һәм коммуналь зоналар.
4. Инженерлык-транспорт инфраструктурасы зонасы.
5. Авыл хуҗалыгы кулланышындагы зоналар.
6. Рекреацион билгеләнештәге зоналар.
7. Махсус билгеләнештәге зоналар.
8. Шәһәр төзелеше регламентлары кагылмый торган җирләр билгеләнми.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына карата
2 нче кушымта
27.09.2022 №2543

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү эшләрен башкару тәртибе һәм сроклары**

| № т/б | Эшләрнең атамасы | Сроклары |
|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар кабул итү турындагы хәбәрне бастырып чыгару | 05.10.2022 елга кадәр |
| 2 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү | 17.10.2022 елга кадәр |
| 3 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын техник регламентларның таләпләренә, җирлекнең генераль планына туры килү-килмәвенә тикшерү | 24.10.2022 елга кадәр |
| 4 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектының техник регламентларның таләпләренә, җирлекнең генераль планына туры килү яисә туры килмәү турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең бәяләмәсен әзерләү | 31.10.2022 |
| 5 | Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать фикер алышулары | 14.11.2022 |
| 6 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре буенча җәмәгать фикер алышулары үткәрү, гавами тыңлаулар беркетмәләрен әзерләү, җәмәгать фикер алышуларның нәтиҗәләре турында бәяләмәләр әзерләү | 12.12.2022 |

| | | |
|---|---|---|
| 7 | Җәмәгать фикер алышулар тәмамланганнан соң, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын, җәмәгать фикер алышуларның беркетмәсе һәм нәтиҗәләре турында бәяләмә кушымталары белән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә тәкъдим итү | 12.12.2022 |
| 8. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан Зеленодольск муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын җибәрү турында карар кабул итү | 19.12.2022 |